ГЛАВА ТАШКИЧУЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.21А, д.Малые
Уруссу, 423959

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 21А йорт, Кече
Урыссу авылы., 423959

Тел.:(85593) 4-23-10, факс:4-23-40, e-mail: Tash.UTz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**

**№ 2** **13 октябрь 2023 ел**

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенең Хөррият торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 9 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14, 81 маддәләре, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2019 елның 25 октябрендәге 17 санлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында»гы нигезләмәнең 4 пунктындагы 4.4 пунктчасы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башлыгы,

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 25 октябрендә 12.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенә керүче Хөррият торак пунктында Татарстан Республикасы Ютазы районы, Хөррият авылы, Хөррият урамы, 5 нче йорты каршында 2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенә керүче Хөррият торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенә керүче Хөррият торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза булырсызмы:

- Хөррият бистәсендә хуҗалык инвентаре өчен зиратта бина төзү (материаллар сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, транспорт чыгымнары).

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар аны игълан иткән көннән (халыкка җиткергәннән) үз көченә керә.

"Ташкичү авыл җирлеге"
муниципаль берәмлек башлыгы Р.К.Вәлиев